РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423983, РТ, Муслюмовский район. с. Баюково, ул. Советская 2,*
*тел. (8-85556)3-16-38*

№ 1 20.02.2019 г.

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл жирлегенең жирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында**

"Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Җирләү һәм күмү эше турында"гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Җирләү һәм күмү эше турында"гы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында"гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Карарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең " 2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында"гы 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл жирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл жирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Баек авыл жирлегендә жирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1нче һәм 2нче кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә расларга һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны "Авыл утлары" район газетасында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл жирлегенең рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Мөслим муниципаль районы Баек авыл жирлегенең Башкарма комитет житәкчесе вазыйфаларын башкаручы М.Ф.Фахерлегаяновка йөкләргә.

**Башкарма комитет житәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **М.Ф.Фахерлегаянов**

Мөслим муниципаль районы Баек авыл
жирлеге Башкарма комитетының
«20 » февраль 2019 ел № 1
карарына 1 нче кушымта

2019 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районы Баек авыл жирлегендә жирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Табутны һәм жирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3200,38 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,76 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,33 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Башкарма комитетының
«20 » февраль 2019 ел № 1
карарына 2 нче кушымта

2019 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 338,05 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2862,35 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,32 |
| Барлыгы | 5946,47 |